Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Кариле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 25 мае №85

2023 елда «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы нигезендә карар чыгарды:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән җирле үзидарә органнарында һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пункты «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Г.Гарифуллин